**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Яңа Усы авыл җирлегенә керүче Яңа Усы авылы**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **03.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге составына керүче Яңа Усы торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Яңа Усы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. Көндезге формада укучы студентларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Яңа Усы авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүгә;
- Яңа Усы авылы мәдәният оешмалары хезмәтләре белән ял вакытын оештыру һәм халыкны тәэмин итү өчен шартлар тудыруга;
- Физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, Яңа Усы авылы җирлегендә рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыруга;
- Яңа Усы авылы җирлегендә рәсми мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыруга;
- Яңа Усы авылы җирлеген төзекләндерүне оештыруга;
- Яңа Усы авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тотуга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүгә, Яңа Усы авылы суларын чыгаруны оештыруга;
- Яңа Усы авылы җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- Яңа Усы авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыруга».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда , Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына һәм Мөслим муниципаль районы, Яңа Усы авылы, Совет урамы, 30 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы** **Г.С. Романова**